КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

622-П № 09.12.2024

Татарстан Республикасы, Минзәлә районы, Минзәлә шәһәре, Җәлил урамы, 15 нче йорт адресы буенча эзләп табылган «Горюхин йорты, XIX гасыр уртасы» мәдәни мирас объектын, Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, Җәлил урамы, 15 нче йорт адресы буенча урнашкан “Шәһәр управасы бинасы", XIX гасыр уртасы., XXI гасыр башы җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты сыйфатында, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) бердәм дәүләт реестрына кертү, мәдәни мирас объектының сак предметын билгеләү, чикләрен раслау турында

2002 нче елның 25 нче июнендә гамәлгә кергән 73-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) турында»гы Федераль законы, 2005 нче елның 1 нче апрелендә гамәлгә кергән 60-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында»гы Татарстан Республикасы Законы, дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының 2024 елның 16 нчы ноябренә караган уңай бәяләмәсенә нигезләнеп боерам:

1. Татарстан Республикасы, Минзәлә районы, Минзәлә шәһәре, Җәлил урамы, 15 нче йорт адресы буенча эзләп табылган «Горюхин йорты, XIX гасыр уртасы» мәдәни мирас объектын, Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, Җәлил урамы, 15 нче йорт адресы буенча урнашкан “Шәһәр управасы бинасы", XIX гасыр уртасы, XXI гасыр башы (объект төре - һәйкәл) җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты сыйфатында, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас

объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) бердәм дәүләт реестрына кертергә.

2. Әлеге боерыкка караган 1нче кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, Җәлил урамы, 15 нче йорт адресы буенча урнашкан “Шәһәр управасы бинасы", XIX гасыр уртасы., XXI гасыр башы җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен расларга.

3. Әлеге боерыкка караган 2 нче кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, Җәлил урамы, 15 нче йорт адресы буенча урнашкан “Шәһәр управасы бинасы", XIX гасыр уртасы., XXI гасыр башы җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектының сак предметын расларга.

4. Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2021 нче елның 21 нче сентябрендә гамәлгә кергән 215-П номерлы “Татарстан Республикасы, Минзәлә районы, Минзәлә район үзәге, Җәлил урамы 15 нче йорт (Татарстан Республикасы, Минзәлә районы, Минзәлә шәһәре, Муса Җәлил урамы 15 нче йорт) адресы буенча урнашкан “Горохин йорты” ачыкланган мәдәни мирас объектының чикләрен һәм куллану режимын раслау турында”гы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Мәдәни мирас объектларын һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеген исәпкә алу бүлегенә, күрсәтелгән мәдәни мирас объекты территориясе чикләре турында белешмәләрне, күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына һәм Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертүне тәэмин итәргә.

6. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас
объектларын саклау
комитетының 2024 елның
9 нчы декабрендәге 622-П
номерлы боерыгына
караган 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, Җәлил урамы, 15 нче йорт адресы буенча урнашкан “Шәһәр управасы бинасы", XIX гасыр уртасы., XXI гасыр башы җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты

**территориясе чикләре**

Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, Җәлил урамы, 15 нче йорт адресы буенча урнашкан “Шәһәр управасы бинасы", XIX гасыр уртасы., XXI гасыр башы җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең картасы (схемасы)




Масштабы 1:1000

Шартлы билгеләр:

| | |
|---|---|
| 1• | - мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең характерлы ноктасы |
| | - мәдәни мирас объекты |
| | - мәдәни мирас объекты территориясе |
| 16:28:180175:103 | - җир кишәрлегенең кадастр номеры |
| | - мәдәни мирас объекты территориясе чикләре |

Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, Җәлил урамы, 15 нче йорт адресы буенча урнашкан “Шәһәр управасы бинасы", XIX гасыр уртасы., XXI гасыр башы җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең текст тасвирламасы

Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, Җәлил урамы, 15 нче йорт адресы буенча урнашкан “Шәһәр управасы бинасы", XIX гасыр уртасы., XXI гасыр башы җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләре түбәндәге урыннардан уза:

| Чикнең узу урыны | | Чикнең узу урынының тасвирламасы |
|---|---|---|
| ноктадан | ноктадан | |
| 1 | 2 | 1 нче ноктадан 28,29 метр ераклыкка көньяк-көнчыгыш юнәлештә, кадастр номеры 16:28: 180175: 103 булган җир кишәрлеге чиге буйлап, 2 нче ноктага кадәр; |
| 2 | 3 | 2 нче ноктадан 45,88 метр ераклыкка көньяк-көнбатыш юнәлештә, кадастр номеры 16:28: 180175: 103 булган җир кишәрлеге чиге буйлап, 3 нче ноктага кадәр; |
| 3 | 4 | 3 нче ноктадан 28,54 метр ераклыкка төньяк-көнбатыш юнәлештә, кадастр номеры 16:28: 180175: 103 булган җир кишәрлеге чиге буйлап, 4 нче ноктага кадәр; |
| 4 | 1 | 4 нче ноктадан 45,77 метр ераклыкка төньяк-көнчыгыш юнәлештә, кадастр номеры 16:28:180175:103 булган җир кишәрлеге чиге буйлап, 1 нче ноктага кадәр. |

Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, Җәлил урамы, 15 нче йорт адресы буенча урнашкан “Шәһәр управасы бинасы", XIX гасыр уртасы., XXI гасыр башы җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни  мирас объекты территориясе чикләренең характерлы нокталар таблицасы

| № | Җирле координаталар системасында характерлы нокталарның координаталары (ҖКС-16) | |
|---|---|---|
| | X | Y |
| 1 | 468520.44 | 2367069.11 |
| 2 | 468494.30 | 2367079.94 |
| 3 | 468478.18 | 2367036.99 |
| 4 | 468504.59 | 2367026.17 |
| 1 | 468520.44 | 2367069.11 |

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас
объектларын саклау
комитетының 2024 елның
9 нчы декабрендәге 622-П
номерлы боерыгына
караган 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, Җәлил урамы, 15 нче йорт адресы буенча урнашкан “Шәһәр управасы бинасы", XIX гасыр уртасы., XXI гасыр башы җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектының

**сак предметы***

1. Урнашу урыны: Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил урамнарының тарихи кызыл сызыклары киселеше.
2. Әйләнә-тирәдәге табигый һәм мәдәни ландшафт структурасында композицион әһәмияте (роле): тарихи квартал почмагын теркәүче ике рәтле төзелешле гади бина.
3. Һәйкәлнең габаритлары, силуэты: тарихи кирпеч диварлар чикләрендә.
4. Һәйкәлнең күләм-киңлек композициясе: турыпочмаклы планда 2 катлы кирпеч бина.
5. Түбә: түбә конфигурациясе (иелмәле); тимераяк буенча Биеклек билгеләре; конструкцияләр материалы (стропилалар һәм агач бизәкләр); түбә япмасының характеры (фальцев кушылмалы шома металл япма). Мич торбалары югалган.
6. Фасадларның композициясе һәм архитектур-сәнгати бизәлеше, тәрәзә һәм ишек уемнарының урнашуын, формасын һәм үлчәмен, цоколь кисемен, рамда профильле тартмалар булган киң кат ара поясны, түбә кәрнизен профильләү һәм беркетүне дә кертеп.
7. Фасад өслегенең бизәлеше: кирпеч өслеге буенча буяу (агарту). Колористик чишелеш: ак төс. Тәрәзә уемнарын тутыру: столярлык (агачтан), күп пыялалы (югалган).
8. Интерьерларның пространство-планлаштыру структурасы: Капиталь диварлар, яссы түшәмәләр һәм гөмбәзләр чикләрендә; бүлмәләрнең планлаштыру элемтәләренең үзенчәлекләре: коридор; ишек һәм тәрәзә уемнарының урнашу урыны, формасы, зурлыгы.
9. Һәйкәлнең конструктив схемасы: ком-известь эремәсендә таштан коелган кирпеч стеналы каркассыз; буй һәм аркылы кирпеч стеналарның урнашуы һәм эшләү материалының тибы (кирпечтән салу); түшәмә материалы: яссы, гөмбәзле (тартма); кыскычларның тибы: клинчатый, распалубки.

* Сак предметы комплексслы фәнни тикшеренүләр һәм реставрация эшләре үткәрү барышында үзгәртелергә мөмкин.

# Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, Җәлил урамы, 15 нче йорт адресы буенча урнашкан “Шәһәр управасы бинасы", XIX гасыр уртасы., XXI гасыр башы җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектының сак предметы таблицасы

| № п/п | **Сак предметы** | **Төп элементларны фотофиксацияләү/график материаллар** |
|---|---|---|
| 1. | Урнашу урыны: Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил урамнарының тарихи кызыл сызыклары киселеше. | <br><br>Шартлы билгеләр:<br>- каралучы объект<br>1 нче рәсем. Объектның урнашу урыны |
| 2. | Әйләнә-тирәдәге табигый һәм мәдәни ландшафт структурасында композицион әһәмияте (роле): тарихи квартал почмагын теркәүче ике рәтле төзелешле гади бина. | <br>2 нче рәсем. Муса Җәлил һәм Габдулла Тукай урамнары киселешеннән гомуми күренеш . |

| | | |
|---|---|---|
| 3. | Һәйкәлнең габаритлары, силуэты: тарихи кирпеч диварлар чикләрендә. | <br>3 нче рәсем. Экспертиза объекты (совет чоры). |
| 4. | Һәйкәлнең күләм-киңлек композициясе: турыпочмаклы планда 2 катлы кирпеч бина. | <br>4нче рәсем . Г. Тукай урамы ягыннан гомуми күренеш. Күләм-киңлек композициясе |
| 5. | Түбә: түбә конфигурациясе (иелмәле); тимераяк буенча Биеклек билгеләре; конструкцияләр материалы (стропилалар һәм агач бизәкләр); түбә япмасының характеры (фальцев кушылмалы шома металл япма). Мич торбалары югалган. | <br>5 нче рәсем. Муса Җәлил урамы ягыннан гомуми күренеш. |

| | | |
|---|---|---|
| 6. | Фасадларның композициясе һәм архитектур-сәнгати бизәлеше, тәрәзә һәм ишек уемнарының урнашуын, формасын һәм үлчәмен, цоколь кисемен, рамда профильле тартмалар булган киң кат ара поясны, түбә кәрнизен профильләү һәм беркетүне дә кертеп. | <br>6 нчы рәсем. Муса Җәлил урамы ягыннан гомуми күренеше (төп фасад). |
| 7. | Фасад өслегенең бизәлеше: кирпеч өслеге буенча буяу (агарту). Колористик чишелеш: ак төс. Тәрәзә уемнарын тутыру: столярлык (агачтан), күп пыялалы (югалган). | <br>7 нче рәсем. Габдулла Тукай урамы ягыннан гомуми күренеш.<br><br>8 нче рәсем. Башындагы фасад. |

| | | |
|---|---|---|
| 8. | Интерьерларның пространство-планлаштыру структурасы: Капиталь диварлар, яссы түшәмәләр һәм гөмбәзләр чикләрендә; бүлмәләрнең планлаштыру элемтәләренең үзенчәлекләре: коридор; ишек һәм тәрәзә уемнарының урнашу урыны, формасы, зурлыгы. | <br>9 нчы рәсем. Гөмбәзле япмалар системасы .<br><br>10 нчы рәсем. Распалубкалы гөмбәзле япмалар системасы . |
| 9. | Һәйкәлнең конструктив схемасы: ком-известь эремәсендә таштан коелган кирпеч стеналы каркассыз; буй һәм аркылы кирпеч стеналарның урнашуы һәм эшләү материалының тибы (кирпечтән салу); түшәмә материалы: яссы, гөмбәзле (тартма); кыскычларның тибы: клинчатый, распалубки. | <br>11нче рәсем. Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил урамнары ягыннан гомуми күренеш |